КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 31 август г.Казань № 761

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә «Белая елгасы дельтасы» комплекслы профильле төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигый тыюлыгын төзү турында

«Аеруча саклаулы табигать территорияләре турында" 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Хайваннар дөньясы турында" 1995 елның 24 апрелендәге 52-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Су кодексы һәм Татарстан Республикасы Экология кодексы нигезендә, Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән табигый комплексларны, үсемлекләрнең һәм хайваннарның су һәм су яны төрләрен саклау максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының Татарстан Республикасының Актаныш муниципаль районы территориясендә 14 956,502 гектар мәйданлы «Белая елгасы дельтасы» комплекслы профильле төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигый тыюлыгын төзү турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Карарга теркәлгән түбәндәгеләрне расларга:

«Агыйдел елгасы дельтасы» комплекслы профильле төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигый тыюлыгы турында нигезләмәне;

«Агыйдел елгасы дельтасы» комплекслы профильле төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигый тыюлыгының чикләре урнашкан урынның график тасвирламасы.

3. Территориаль планлаштыру документларын эшләгәндә, җирләрне инвентаризацияләгәндә «Агыйдел елгасы дельтасы» комплекслы профильле төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигый тыюлыгының чикләрен һәм махсус саклау режимын исәпкә алырга.

4. Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасының махсус саклана торган табигать территорияләре дәүләт реестрына тиешле үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын тәкъдим итәргә;

«Агыйдел елгасы дельтасы» комплекслы профильле төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигый тыюлыгы чикләре турында мәгълүматларны «Дәүләт теркәве, кадастры һәм картографиясе федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына билгеләнгән тәртиптә финанслар бүлеп бирелгәннән соң бер ел эчендә тапшыруны тәэмин итәргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин